ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.07.2026 ел Баулы шәһәре № 600

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге территориясендә
су белән тәэмин итү һәм суны агызу
буенча гарантияләүче оешманы
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2011 елның 7 декабрендә «Су белән тәэмин итү һәм суны агызу турында» 416-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесеннән «Электр челтәрләре» (ОГРН 1051641034807) 2026 елның 15 маендагы ГУП443 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 июленнән Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә салкын су белән тәэмин итүнең һәм су агызуның үзәкләштерелгән системалары буенча гарантияләүче оешма итеп расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен салкын су белән тәэмин итүнең һәм суны агызу үзәкләштерелгән системасы буенча гарантияли торган оешма эшчәнлеге территориясе итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Сафиуллин